| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 ноября 2023 г. с.Шалты № 24

**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

- 2023 елның 24 ноябренә 10:00 сәгатькә Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә. Халык җыенын үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Шалты авылы, Совет урамы, 63Б адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты

- 2023 елның 24 ноябренә 14:00 сәгатькә Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә. Халык җыенын үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Шалты авылы, Новая урамы, 6 адресы буенча урнашкан МББУ “Шалты төп гомуми белем бирү мәктәбе”

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2024 елда Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге Шалты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан һәм Россия

Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яки контракт буенча хәрби хезмәткә кергән яки Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарның гаиләләреннән тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- Шалты авылында традицион җирләү урыннарын төзекләндерүне оештыру өчен трактор өчен прицеплы арба сатып алу;

- Юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (кар һәм чүп үләннәреннән чистарту)

2. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә Шалты авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шалты авыл
җирлеге Башлыгы З.Х. Фаткуллин